**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«04» ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 4 ноябрендә узган:

«Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү максатыннан сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу, сууткәргеч челтәрләрне реконструкцияләү, яңа сууткәргеч челтәрләр үткәрү буенча төзелеш-монтаж эшләрен башкару өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Киекле авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, кирпеч, грунт, вак таш, ком, асфальт (сатып алу, ташу, салу), чокырларны ямау (сыек асфальт);

- Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

авыл җирлегенең торак пунктларындагы урамнарны, территорияләрне, Киекле авылындагы өч зиратны төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу, коймаларны буяу);

- Киекле авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм уздыру өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Киекле авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Киекле авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 698 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 394 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 372 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 22 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр

кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү максатыннан суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу, суүткәргеч челтәрләрне реконструкцияләү, яңа суүткәргеч челтәрләр үткәрү буенча төзелеш-монтаж эшләрен башкару өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Киекле авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, кирпеч, грунт, вак таш, ком, асфальт (сатып алу, ташу, салу), чокырларны ямау (сыек асфальт);

- Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

авыл җирлегенең торак пунктларындагы урамнарны, территорияләрне, Киекле авылындагы өч зиратны төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу, коймаларны буяу);

- Киекле авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм уздыру өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Киекле авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Киекле авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Киекле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова